Чыганак: Шәһри Казан. - 1997. - 1 окт.

**ФӘННЕҢ яңа тәрәнә - этнологиягә нигез салучы күренекле галим Лев Гумилевның тууына 85 ел. Тарихчы буларак ул Азиянең очсызкырыйсыз далаларында яшәгән, рус дәүләте белән тыгыз мөнәсәбәттә торган борынгы халыклар һәм дәүләтләр турында яңа тикшеренүләр, ачышлар ясап калдырды.**

**Ул безнең кем икәнлегебезне, туганнарыбызның кем булуын аңлатып бирде.**

# ЙӨРӘГЕНДӘ АНЫҢ - ВАКЫТ АГЫШЫ

Бер офыктан икенче офыккача җәелгән, иге дә, чиге дә күренмәгән Бөек Дала күкрәгендә ап-ак кылганнар диңгезе чайкала. Югарыдан, биектән пар бөркет кояш чыгышына карап оча. Шул олуг кызыл табак - кояшның беренче нурларыннан уянып, кылганнар диңгезен ярып ерак кардәшебез һун егете сөлектәй сузылып, томырылып чапкан алмачуар аргамакта җилдерә. Аның мөгездән ясалган җәясеннән атылган ук пар бөркетләр эзе буйлап оча. Бу очышның һаман тукталганы юк. Ул ничәмә-ничә гасырдәверләр чиген узып, безнең көннәрне дә үзенә ияртеп, киләчәккә карап иге дә, чиге дә булмаган галәм ишеген ачып, Киек Казлар Юлы буйлап якты эз сызып бара. Вакытның ул бөек көче. Аны берәү дә туктата алмый. Вакытны фәкать вакыт кына тудыра. Асыл акыл ияләре генә вакыт агышын кайнар учларында тотып, үз йөрәгенә сыйдыра.

Беркайчан да Вакыт Ялган белән бергә була алмый. Һун егете аткан ук барыбер дә Хаклык, Хакыйкать сүзен әйтә. Галиҗәнап Вакытның илаһи шушы серен ачып биргән даһи затларның берсе безнең даһи чордашыбыз Лев Николаевич Гумилев.

Берәүдән дә, берәүгә сер түгел: безнең халыкны моңарчы тарих китапларында һәрдаим кара яктан сурәтләп килделәр. Тәрәзәне каплап кояш үткәрмәскә мөмкин. Вәләкин вакыт агышын, акыл көчен зинданнарга да ябып булмый. Вакыт дулкыны ташларның үзәгенә үтеп керә. Ком катламнары астында күмелеп калган орлыктан мәхәббәт һәм гайрәтле Яшәеш агачы калкып чыга.

Аурупа, шул җөмләдән безнең белән бакый гомер иңгә-иң терәшеп яшәгән Русия Шәрык мохитен, Бөек Дала илен инкарь итеп килде. Вакыт җимеше - тарих китабына ул ялган юллар тезде. Безне кыргыйлыкта гаепләде.

Рәхмәт сезгә, даһи галим Лев Николаевич. Вакытның хакыйкать дип аталган, кемнәрдер өчен мәңге ачылмас дип фараз кылынган яшерен серле чикләвеген ачып, Хаклык сүзен бөтен ил, бөтен дөнья күләмендә әйтеп бирдегез:

**- Татарлар варварлар түгел!**

Бактың исә, Чыңгыз хан, Батый хан Русьны юк итүдән бигрәк, аны саклап калганнар. Бу фикерне ерак вакыт төпкеленә кереп чорналган чорларның һәр чаң, һәр тузанын күздән кичереп, һәр сүзне кайтадан-кайта өйрәнеп, аның тирән мәгънәсенә төшенеп, киңәшеп, үз йөрәге аша кичереп Лев Гумилев әйтте.

Шуңа да без бу олуг фикер иясенә рәхмәтлебез. Бездән соңыннан килгән буыннар бәлки ул рәхмәт сүзен тагын да зурлабрак әйтерләр әле.

Изгеләрдән генә изгеләр туа. Лев Николаевич зыялы нәселдән. Аның әнисе Анна Ахматова рус халкының гына сөекле шагыйрәсе түгел, аны без дә үз итәбез. Йөрәгендә татар каны да булуы белән горурланган ул. Җәбер, золым хакимлек кылган чорда да фамилиясен Әхмәт исеме белән йөрткән. Левның әтисе Николай Гумилев - русның зур шагыйре. Ул да үзенә үлем янаган минутта дусларын сатмаган. Бөек хаклык хакына җанын фида кылган. Уллары Левка да шушы рух, кешеләрне, барча милләт вәкилләрен ярату хисе балачактан сеңгән. Казанда яшәгән бер галимгә язган хатын ул: **"Сезнең Арсланыгыз!"** - дип тәмамлый.

Әйе, Лев Николаевич вакыт кодрәтен үз йөрәгенә туплаган безнең дә кыю Арсланыбыз!

Аның үз гомере дә бормалы, сыгылмалы елга агышы кебек. Бу елганы кояш нурлары гына иркәләп тормаган. "Халык дошманы" буларак төрмәләрдә иза чигүләр, дуслары-фикердәшләре белән күрешә алмау, әнисеннән читтә еракта булу, каһәрләнү, танылмау, фронт юллары буйлап узу - аның гомер агышы әнә шундый... Ләкин хакыйкать дип аталган вакыт угының очышыннан тукталганы юк. Бүген әлеге галим кулы белән язылган китаплар кулдан-кулга күчеп йөриләр. Җир йөзендә яшәгән халыклар тарихы Бөек Даладан аерылгысыз. Ап-ак кылганнар дулкыны биек кыяларга килеп кагыла. Ә ул кыялар итәгеннән меңләгән елларның, ерак-озын дәверләрнең катламнарын үтеп чыккан зәңгәр күзле чишмәләр галәмгә бага. Алар киң галәмне иңләп очкан вакыт угына үз сәламнәрен юллыйлар.

**Госман САДЭ.**